| | |
|---|---|
| БАВЛИНСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2018 елның 13 декабрь Баулы шәһәре № 97

Баулы шәһәр Советының
«Җир салымы турында»
2014 елның 11 ноябрендә кабул ителгән
114нче санлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32нче бүлеге нигезендә Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы шәһәр Советының 2014 елның 11 ноябрендә кабул ителгән «Җир салымы турында»гы карарына (Баулы шәһәр Советының 2016 елның 28 сентябрендәге 43нче санлы, 2017 елның 15 июнендәге 53нче санлы, 2017 елның 25 октябрендәге 61нче санлы, 2017 елның 15 декабрендәге 67нче санлы, 2018 елның 16 ноябрендәге 92нче санлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

4 пунктны түбәндәге пунктчалар белән тулыландырырга:

«7) 18 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнар.».

2. Салым ташламасы гаиләнең бер җир кишәрлегенә карата (үзләре сайлау буенча) бирелә.

3. Салым ташламасы Баулы шәһәре территориясендә даими яшәүче салым түләүчеләргә салым түләүче милкендә булган һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлегенә карата бирелә.

4. Салым ташламасына хокукы булган зат салым органына ташламалар бирү турында гариза һәм салым ташламасына хокукын раслаучы документлар тапшыра.

5. Салым түләүче мөрәҗәгатьне җир кишәрлегенә карата салым ташламасы кулланыла торган салым чоры булган елның 1 ноябренә кадәр салым органына тапшыра».

6. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә (ләкин аны Татарстан Республикасы http://pravo.tatarstan.ru хокукый мәгълүмат рәсми порталында рәсми басылып чыккан көннән соң бер айдан да иртәрәк түгел) һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карый.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый рәсми мәгълүмат порталда бастырып чыгарырга һәм Баулы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Баулы шәһәре мэры,
шәһәр Советы рәисе

Р.Х. Гатиятуллин